РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330
Тел. факс (885592) 7-15-50
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ

Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. факс (885592) 7-15-50
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

от 09.12.2019 г.　　　　　　　　　　　　№ 273

.

2019-2020 елларда кышкы чорда
Азнакай шәһәре урамнарыннан, паркларыннан
һәм скверлардан карны вакытлыча саклау территориясен
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2006 елның 19 маенда кабул ителгән 28-6 номерлы «Азнакай шәһәрендә тышкы төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләре турында (14.07.2006 № 44-7, 15.05.2008 № 92-24, о01.12.2009 № 147-39, 29.04.2010 № 166-44, 26.05.2011 № 33-8, 12.07.2012 № 72-20, 23.08.2013 №99-30, 22.05.2014 №123-38, 29.12.2014 №154-44, 29.09.2017 № 55-18, 19.04.2018 № 93-25, 22.04.2019 № 133-32 крарлар редакциясендә) карарын үтәү йөзеннән:

1. Азнакай шәһәренең урам юл челтәрен, шәһәрнең сәнәгать предприятиеләре һәм оешмалары өчен шәһәр урамнарыннан, мәйданнарыннан, паркларыннан һәм скверларыннан карны вакытлыча җыеп тору һәм чыгару өчен территорияне билгеләргә:

- шәһәр мәйданы янындагы ипподром кыры янында асфальт өслеге (мәйданы – 6051 кв.м., координатлары – 54.8854º-53.0711º, җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:02:050108:15).

2. Азнакай шәһәренең урам-юл челтәрен карап тотучы сәнәгать предприятиеләренә һәм оешмаларына, предприятиеләренә, әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән территориягә карны чыгару һәм вакытлыча өеп куюны һәм карны бетергәннән соң, җир кишәрлегенең бөтенлеген бозмыйча, экологик законнарга туры китерүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Житәкче　　　　　　　　　　　　М.И.Солтанов